КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 декабрь г.Казань № 1209

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче; 2016 ел, 17 август, 568 нче; 2016 ел, 7 декабрь, 904 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 971 нче; 2017 ел, 27 март, 188 нче; 2017 ел, 29 август, 611 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 711 нче; 2018 ел, 25 май, 398 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1215 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 25 июль, 619 нчы; 2019 ел, 13 ноябрь, 1038 нче; 2020 ел, 3 февраль, 68 нче; 2021 ел, 20 июль, 607 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1095 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 21 апрель, 383 нче; 2022 ел, 16 август, 838 нче; 2023 ел, 2 март, 198 нче; 2023 ел, 27 май, 644 нче; 2023 ел, 15 сентябрь, 1133 нче; 2024 ел, 27 май, 369 нчы; 2025 ел, 12 июль, 507 нче; 2025 ел, 18 октябрь, 838 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хезмәткәрләренең иң чик санын түбәндәгечә билгеләргә:

аппарат буенча – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 5 643,1 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 171 берәмлек, шул исәптән «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Буага караган ипподромлы» дәүләт завод ат абзары»

дәүләт учреждениесе, «Чистайга караган ипподромлы» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесе һәм «Минзәләгә караган ипподромлы» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесенең бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык хисапларын формалаштыру һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакын исәпләү максатларында вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 47,4 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 2 берәмлек күләмендә;

муниципаль районнардагы территориаль органнар буенча – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 12 646,5 мең сум күләмендәге айлык фонды белән 516 берәмлек күләмендә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе әгъзалары санын һәм составын раслау турында» 2022 ел, 14 март, 229 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 12 июль, 507 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

коллегия составына Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Нияз Фәнис улы Хурамшинны кертергә.

3. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин